РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423950, п.г.т. Уруссу, ул. Пушкина, д.38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

423950, Урыссу ш.т.б., Пушкин урамы, 38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 14 » 12 2020 г. №940

“Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының 31.08.2020 ел, № 658 “2020 елда Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләре укучыларын туклandыруны оештыру турында” карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясенең «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 29.12.2012 ел, № 273-ФЗ Федераль законы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Мәгариф турында документлар һәм (яки) квалификация турында, белем алу турында документлар турында мәгълүматларның федераль реестры” федераль мәгълүмат системасы турында» 2013 елның 26 августындагы 729 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының «2020 елда Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләре укучыларының туклануын оештыру турында» 31.08.2020 ел, №658 Карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

“2. Әлеге Нигезләмә укучыларны кайнар аш белән тәэмин итүне оештыру максатларында гомуми белем бирү учреждениеләрендә түбәндәге категория укучылары өчен эшләнде:

Россия Федерациясе Президентының «Күп балалы гаиләләргә социаль ярдәм чаралары турында» 1992 елның 5 маендагы 431 номерлы Указы нигезендә, 18 яшькә кадәрге 4 һәм аннан да күбрәк баласы булган гаиләләрдәге балаларга ике тапкыр түләүсез туклану (иртәнге һәм төшке аш) белән тәэмин итү каралган. Ташламалы туклану, гомуми белем бирү учреждениеләрендә гаиләдәге өч һәм аннан да күбрәк бала белем алса, әлеге категориядәге укучыларга бирелә;

- әти-әниләре 1 һәм 2 нче группа инвалидлык алган балаларга;

- опекага алынган балаларга (Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек органнары белән килешенеп).

Әлеге категориягә керүче балаларга адреслы социаль ярдәм 2020 елга гомуми белем бирү учреждениеләренең расланган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә Ютазы муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләрендә ата-аналар түләвеннән өлешчә азат итү юлы белән гамәлгә ашырыла.».

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Интернет-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль сораулар буенча урынбасарына йөкләргә.

Ютазы муниципаль районы

Башкарма комитет җитәкчесе С. П. Самонина

Гыйләҗева Г. М.

885593(2-90-68)